КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 28 апрель г.Казань № 638

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына грант ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 14 июль, 572 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына грант ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 14 июль, 572 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 29 октябрь, 1013 нче, 2022 ел, 11 май, 428 нче, 2022 ел, 10 сентябрь, 976 нчы, 2023 ел, 20 апрель, 500 нче, 2023 ел, 8 июль, 805 нче, 2024 ел, 25 июнь, 457 нче, 2024 ел, 28 декабрь, 1241 нче, 2025 ел, 24 май, 354 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

дүртенче - алтынчы абзацлар үз көчләрен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Крестьян (фермер) хуҗалыкларына фермер хуҗалыгын үстерүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган грант бирү тәртибе;

Татарстан Республикасы бюджетыннан махсус хәрби операциядә катнашучыларга федераль бюджеттан финанслана торган «Агромотиватор» грантын бирү тәртибе;

Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының матди-техник базасын үстерү өчен авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына Татарстан Республикасы бюджетыннан грант бирү тәртибе;

Кече авыл икмәкханәсен оештыру проектын тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслана торган грант бирү тәртибе.»;

әлеге карар белән расланган Агросәнәгать комплексы өлкәсендә фәнни тикшеренүләргә һәм эшләнмәләргә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен бюджет

учреждениеләренә һәм автоном учреждениеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан грант бирү тәртибендә:

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Грант турында мәгълүмат грант бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба тиешенчә – бердәм портал, «Интернет» челтәре) Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

9.9 пунктта «исәп-хисап яисә корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

10.5 пунктта «Бирелгән грантлар» сүзләрен «Грант акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Яңа эш башлаучы авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының матди-техник базасын үстерүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан грант бирү тәртибендә:

1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Грант турында мәгълүмат грант бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба тиешенчә – бердәм портал, «Интернет» челтәре) Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

9.9 пунктта «исәп-хисап яисә корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

10.7 пунктта «Бирелгән грантлар» сүзләрен «Грант акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карарга Крестьян (фермер) хуҗалыкларына фермер хуҗалыгын үстерүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган грант бирү тәртибен, Татарстан Республикасы бюджетыннан махсус хәрби операциядә катнашучыларга федераль бюджеттан финанслана торган «Агромотиватор» грантын бирү тәртибен, Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының матди-техник базасын үстерү өчен авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына Татарстан Республикасы бюджетыннан грант бирү тәртибен, Кече авыл икмәкханәсен оештыру проектын тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслана торган грант бирү тәртибен өстәргә (карарга теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин